РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29,
Тел. 3-44-56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур., 29 нчы йорт. Тел.3-44-56

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«13» июль 2021 ел** **№ 12**

**Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге Советының 20.06.2016 ел, № 13 карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлегенең бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «3. Агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары, муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре исәпкә алына».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Иске Кормаш авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Иске Кормаш авыл җирлеге Советы рәисе И.Ә.Кашбразиев